

2025 елнын 14-16 ноябрь коннәрендә донья кvләмендә татар телен саклау һәм vстерvгә багышланган «Татарча диктант» акциясе узды. Мордовия буйлап диктантны торле мәктәпләрдә, дәvләт оешмаларында, институтта, торле Үзәкләрдә яздылар.
«Татарча диктант» беренче тапкыр 2016 елда уздырылган, анда берничә тобәк кенә катнашкан, ә хәзер исә акциядә катнашучылар географиясе ел саен vсә. Быел акциядә 74 Россия тобәге һәм 31 чит ил катнашкан. Катнашучылар саны 1 миллионнан узып киткән.

Акциянен максаты - татар теленә кызыксынуны арттыру, әдәби телдә дорес сойләм һәм дорес язу кvнекмәләрен vстерv, шулай ук донья буенча таралып яшәгән татарларны берләштерv, әдәби татар телен кулланучыларнын даирәсен арттыру. Акциядә катнашуны онлай һәм офлайн башкару каралган иде. «Татарча диктант»нын трансляциясе ТНВ каналында, RUTUBEта да, YOUTUBEта да бар иде. Теләгән барлык кешегә диктант язу момкинчелеге тудырылды.




Быелгы акция мәшһvр галимебез Каюм Насыйринын тууына 200 ел тулуга багышланды һәм бу унайдан Татарстан белән Башкортостанда анын «Кабуснамә», ә чит илләрдә «Әбvгалисина» хезмәтләреннән диктант яздылар. Россия тобәкләрендә яшәvче милләттәшләребез, шул исәптән Мордовиябездә, Мохәммәт Мәһдиевнен «Жир йозендә алты кыйтга» юлъязмасыннан озек яздык.
Дубенка районы С.И.Дергачев исемендәге Кочкурово урта мәктәбе ел саен vткәрелә торган «Татарча диктант» акциясендә катнашалар. Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты предметы буенча озак еллар дәвамында белем бирvче, мәктәп директоры урынбасары Альфия Кетдюс кызы Узбякова *(1нче фотода)* оештырды һәм vткәрде. Мохәммәт Мәһдиевнен «Жир йозендә алты кыйтга...» әсәреннән озек яздылар. Әлеге акциядә катнашкан һәрбер укучыга Рәхмәт хатлары тапшырылды. Альфия Кетдюс кызы vзенен фикерләре белән дә уртаклашты:
- Диктант язу акциясендә укучыларыбыз теләп катнашты. Ин моһиме – татар теленә игътибар жәлеп итv, кызыксыну уяту, теле-безгә мәхәббәт тәрбияләv, уку-чыларыбызнын ойләрендә дә эти-әниләре белән татар телендә сойләшvгә ондәv булды.
Саранскнын Рухи-мәдәни vзәге мәйданчыгында да «Татарча диктант» ботендонья мәгариф акциясе узды. Мордовия халкы ел саен әлеге акциягә кушыла, татар телен

яратуларын кvрсәтә, белемнәрен тикшерә. Рухи-мәдәни vзәк, республикабыз «Якташлар» җәмгыятчелеге хезмәткәрләре һәм барлык яшьтәге битараф булмаган кешеләр диктантны унышлы язды-лар.
Ләмберә районы Кривозерье урта мәктәбе укучылары да «Татарча диктант» ботендонья акциясендә катнашты. Диктант текстын гомерен балаларга татар теле һәм әдәбияты буенча тырышып белем биргән хөрмәтле педагог Луиза Низаметдин кызы Смакаева *(2нче фотода)* житәкчелеге астында vтте. Укучылар ел саен vткәрелә торган «Татарча диктант» акциясендә әдәби татар теле буенча белемнәрен арттыралар, орфографик һәм грамматик яктан vз-vзләрен тикшерәләр.
Акциядә катнашучылар саны ел саен арта бара, бу торле яшь торкемнәре арасында татар телен ойрәнvгә кызыксынунын артуы турында сойли. Саранск шәһәрендә «Татарча диктант» акциясендә жәмәгать һәм дин әһелләре, мәгариф хезмәткәрләре, мәктәп укучылары, студентлар һәм башка бик кvпләр катнаштылар. Саранск кооператив институтында да ике зур аудиториядә «Татарча диктант» яздылар. Диктант башланыр алдыннан Ботендонья акциясендә катнашучыларны сәламләп институт ректоры, дин һәм бизнес әхелләре, укытучылар диктант язучыларны котлау сvзләре белән чыгыш ясадылар. Аннары Мордовиянен танылган татар язучылары һәм шагыйрьләре, аларнын татар телен һәм мәдәниятен саклауга керткән олешләре турында сойләделәр.
Ромоданово районы Белозерье урта мәктәбенен жиденче сыйныф укучылары Габдрашитова Хәят, Хәбибуллова Хадия Габдулла 

Тукайнын туган якка мәхәббәт турында «Туган жирем» шигырен яттан сойләделәр. Диктант текстын хормәтле Раилә Хафиз кызы Ипкаева белән Равил Сәйяф улы Миняев укыды.
Ромоданово районы Алтар урта мәктәбе укытучылары һәм укучылары *(3нче фотода)* Саранск кооператив институтында vткән «Татарча диктант» акциясенә кушылдылар. Чара тәмамланганнан сон диктант язган укучыларга София Вәлиевадан татар орнаментлары тошерелгән буяу-китаплар бvләк иттеләр.
Мин - зур жәмгыятьнен бер олеше. Ел саен диктантны кадерле укытучым әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасынын һәм Россия Федерация-сенен атказанган мәдәният хезмәткәре Фоат Галимулла улы Галимуллин укыган текстларны язып киләм. Икенче ел ике текст язам. Быел Каюм Насыйринен “Кабуснамә” әсәреннән һәм Мохәммәт Мәһдиевнен «Жир йозендә алты кыйтга» юлъязмасыннан озекләрне язып ике кон телевизор алдында булдым. Минем шикелле диктант язучылар Мордовиябезнен торле почмагында яшәгән авыл халкы булды. Акциядә катнашып туган татар телебезне кадерләп сакларга тырышабыз.

**Наилә НАСЫРОВА**